РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

10.12.2021　　　　№ 1411-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
“Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның
бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан
Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан
субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2019
елның 2 апрелендәге 316-п номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Авыл хуҗалыгы культураларының сыйфатын күтәрү максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2019 елның 2 апрелендәге 316-п номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“агымдагы финанс елының 1 маена кадәр барлык авыл хуҗалыгы культураларының кимендә 300 гектар чәчүлек мәйданы булган алучы тарафыннан 2021 ел уңышы өчен минераль ашламалар сатып алуы”;

**1.2.** 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр 2021 ел уңышы өчен сатып алынган минераль ашламалар бәясенең 100% күләмендә һәм өстәлгән бәягә салымны һәм транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча бирелә.”;

**1.3.** 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Субсидия бирү турында хәбәр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында, субсидия бирү турында гаризалар кабул итү тәмамланган датага кимендә ун көн кала урнаштырыла.

**1.4.** 7 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“агымдагы финанс елының 1 маена кадәр барлык авыл хуҗалыгы культураларының кимендә 300 гектар чәчүлек мәйданы булган алучы тарафыннан 2021 ел уңышы өчен минераль ашламалар сатып алуны раслый торган документларның (китерү шартнамәсе, түләү йөкләмәләре яисә башка документлар) күчермәләре;”.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы, Җитәкче урынбасары –
Саба муниципаль районы Башкарма
комитеты аппараты Җитәкчесе М.Р. Кәримов